Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Биклән авылы

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«21» ноябрь, 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Биклән авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2021 елда яшәү урыны буенча Биклән авыл җирлеге Биклән авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Ахметшин урамында урнаштырылачак балалар мәйданчыгы өчен уен элементлары сатып алу ;
- Биклән авылы эчендәге юлларны, китереп бирү ысулы белән,вак таш (щебень) сатып алып,төзекләндерү;
- Чкалов һәм Мәгариф урамнарына җәяүлелр өчен тротуар төзү;
- Ахметшин һәм Чкалов урамнарын тоташтыручы җәяүлеләр басмасын яктылык челтәре сузып,җәяүлеләр өчен тротуар җәеп төзекләндерү;
- масса-күләм спорт белән шөгыльләнү өчен спорт инвентарьлары сатып алу;
- Биклән авылына керү юлын яктырту өчен яктылык челтәре төзү һәм кирәкле электр материаллары сатып алу.

2. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Биклән авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Биклән авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Биклән авыл җирлеге Башлыгы М. Ш. Сәхбеев